Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № III-1**

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 16 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Уставына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсе, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 88, 89, 90 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2015 елның 3 апрелендәге XLVIII-1 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 15.07.2016 ел XI-1, 24.07.2017 ел XX-1, 12.04.2018 ел XXX-1, 01.04.2019 ел XLI-1, 24.09.2019 ел XLV-1 номерлы карарларына ярашлы рәвештә кертелгән төзәтмәләр белән) кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда юстиция органнарына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алынганнан соң http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсенең 8 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 90 маддәсенең 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарга бирелгән кушымтаның 2 һәм 3 пунктлары 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көчләренә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Ф.Г. Әхмәтҗанова

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2020 елның 16 октябрендәге
III-1 номерлы карарына
кушымта №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 7 маддәнең 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 16 пунктча өстәргә:

"16) полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәрнең күрсәтелгән вазыйфаны биләве чорында торак урыны бирү.";

2) 20 маддәнең 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

"3. инициатив проектны тормышка ашыру тәкъдим ителә торган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында яки аның бер өлешендәге уналты яшькә җиткән яшәүчеләрне (-ң) – бу инициатив проектны хуплау турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен"

3) 20 маддәнең 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Гражданнардан сораштыруны билгеләү турында карар район Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен муниципаль берәмлекнең "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты файдаланылырга мөмкин.

Район Советының гражданнардан сораштыруны билгеләү турындагы карарында түбәндәгеләр тәгаенләнә:

1) сораштыруны уздыру датасы һәм сроклары;

2) сораштыру уздырганда тәкъдим ителә торган сорауның (сорауларның) формулировкасы (тәгъбирләнеше);

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру кәгазенең рәвеше;

5) сораштыруда катнашучы муниципаль берәмлек халкының минималь саны;

6) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып гражданнардан сораштыру үткәрелгән очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү (таныклау) тәртибе;.

4) 27 маддәнең 7 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7. Район Советының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутаты түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) шәхсән яки ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш коммерциячел яки коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси фирка, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яисә башка җәмәгать оешмасының, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашу;

б) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәрнамә җибәреп коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси фирка, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яисә башка җәмәгать оешмасының, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан гайре);

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең бүтән берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда күздә тотылган башка очраклар;

3) мөгаллимлек, фәнни һәм бүтән иҗади эшчәнлектән тыш башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса;

4) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтчелек советлары, коммерциягә карамаган хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә эш алып баручы аларның структур бүлекчәләре составына керергә.";

5) 39 маддәнең 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Район Башлыгы түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) шәхсән яки ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш коммерциячел яки коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси фирка, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч

профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яисә башка җәмәгать оешмасының, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашу;

б) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазифаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәрнамә җибәреп коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашу (сәяси фирка, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яисә башка җәмәгать оешмасының, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан гайре);

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең бүтән берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда күздә тотылган башка очраклар;

3) мөгаллимлек, фәнни һәм бүтән иҗади эшчәнлектән тыш башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса;

4) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтчелек советлары, коммерциягә карамаган хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә эш алып баручы аларның структур бүлекчәләре составына керергә.";

6) 42 маддәнең 8 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8. Үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы район Башлыгы урынбасары түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) шәхсән яки ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш коммерциячел яки коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси фирка, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә

катнашу, съездда (конференциядә) яисә башка җәмәгать оешмасының, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашу;

б) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазифаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәрнамә җибәреп коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашу (сәяси фирка, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яисә башка җәмәгать оешмасының, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан гайре);

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең бүтән берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда күздә тотылган башка очраклар;

3) мөгаллимлек, фәнни һәм бүтән иҗади эшчәнлектән тыш башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса;

4) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтчелек советлары, коммерциягә карамаган хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә эш алып баручы аларның структур бүлекчәләре составына керергә.";

7) 57 маддәнең 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Муниципаль вазыйфаны даими булмаган нигездә биләүче затка әлеге маддәнең 2 өлешендәге 1 - 4 һәм 10 пунктларында күздә тотылган гарантияләр бирелә, аның тарафыннан муниципаль вазифаны биләү белән бәйле чыгымнарны каплау гарантияләнә, шул исәптән муниципаль вазифа биләүгә бәйле рәвештә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә хезмәт командировкалары белән бәйле чыгымнарны, шулай ук дәвамлылыгы Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль берәмлек уставында билгеләнә торган чорга эш (вазыйфа) урынын саклау гарантияләнә һәм ул тулаем алганда аена җыенысы ике эш көненнән кимрәк һәм алты эш көненнән күбрәк була алмый.".

8) 70 маддәнең 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 2 абзац өстәргә:

“Прокурор үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру барышында гамәлдәге муниципаль норматив хокукый актларны камилләштерү кирәклеген билгеләгәндә муниципаль норматив хокукый актларны үзгәртү, юкка чыгару яки кабул итү турында проектлар һәм тәкъдимнәр кертергә хокуклы”.

9) 84 матдәнең 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Муниципаль әҗәт (-кә) алулар дигәннән дәүләт (муниципаль) кыйммәтле кәгазьләрен урнаштыру юлы белән һәм заемчы буларак гавами-хокукый берәмлекнең бурыч йөкләмәләре барлыкка килә торган кредитлар рәвешендә заем акчаларын гавами-хокукый берәмлек исеменнән гавами-хокукый берәмлек бюджетына җәлеп итү аңлашыла.”

10) 2021 елның 1 гыйнварына чаклы 79 матдәнең 3 өлешенең, 84 матдәнең 5 өлешенең гамәлдә булуын туктатып торырга.